وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا


Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№5 (174). 1 февраль 2013 / 20-рабыгыль-әүвәл-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Вәгъдәдә тору – иманнан ▷2◁



Төрки-болгар-татарларның экстремизм идеологиясен кисәтү буенча тарихи тәҗрибәсе ▷3,4◁



Адлер ТИМЕРГАЛИН: "Әгәр кальбендә Аллаһ юк икән, синдә әхлак та юк!!" ▷4◁

## Казанда Мәүлид бәйрәме үтте

**28 гыйнвар көнне Г.Камал театрында Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көненә багышланган Мәүлид бәйрәме үткәрелде. Бәйрәмдә вәгазьләр сөйләнде, мөнәҗәтләр укылды, сөекле Пәйгамбәребезгә (сгв) салаватлар әйтелде. Чараны Татарстан мөфтияте оештырды.**

Отто фон Бисмарк, Карл Маркс, Лев Толстой, Жак-Ив Кусто пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) шәхесе алдында баш игән, чөнки нәкъ менә Пәйгамбәребез (сгв) таркау хәлдә яшәгән гарәп кабиләләрен берләштереп, гарәп илен җаһилияттән яктылыкка, алгарышка алып чыга. Пәйгамбәребезнең (сгв) төп коралы - Коръән һәм шәхси үрнәк булган.

Бәйрәмгә Россиянең төрле төбәкләреннән һәм республикабыз районнарыннан рәсми вәкилләр, җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре чакырылган иде. Алар арасында ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов, Мәскәү шәһәре мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов, Хант-Манси - Югра автономияле округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматов, Дагстан Республикасы мөфтие урынбасары Мөхәммәт Мөхәммәтов, Россия ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин һ. б. бар иде. Алар, залга җыелган халыкны сәламләп, бәйрәм белән котлады, Пәйгамбәребезнең (сгв) үгет-нәсыйхәтләре белән уртаклашты.

Чара Коръән аятьләре уку белән башланып китте, алга таба Рәсүлебезнең (сгв) асыл сыйфатлары макталды. РИУ мөгаллиме Ильяс Халиков, республикабызның "Сорнай" фольклор ансамбле, Төркия җырчысы Фаати Ходжа (Хуҗа) башкаруында дини эчтәлекле җырлар яңгырады. Татарстанның халык артистлары Зөһрә Сәхәбиева, Флера Сөләйманова, Миңгол Галиев, Бөгелмәдән килгән "Мирас" халык фольклор ансамбле мөнәҗәтләр башкарды. Г.Камал театры музее мөдире, сүз остасы Луара Шакирҗан Г.Тукайның "Нәсер" шигырен укыды.





Быелгы Мәүлид бәйрәмендә яшьләр дә актив катнашты. Әйтик, Дагстаннан килгән "Рисалә" төркеме дә берничә нәшид укыды.

Бәйрәм республикабыз имам-мөхтәсибләренең вәгазьләре белән үрелеп барды.



## Мәүлид галимнәрне "түгәрәк өстәл"гә җыйды

**29 гыйнвар көнне Казандагы Мәрҗани мәчетендә "Ислам традициясендә Мәүлид ән-Нәби" дип аталган темага "түгәрәк өстәл" сөйләшүе узды. Мәүлид бәйрәме уңаеннан мондый зур чара республикабызда тәүге тапкыр оештырылды.**



Әлеге "түгәрәк өстәл" Пәйгамбәребезнең (сгв) туган көнен үткәрү, Мәүлид аенда чаралар үткәрү өчен фәнни/дини карашларны ачыклау һәм барлау максатыннан оештырылды. Мәүлид бәйрәме мәдәни, тәрбияви, фәнни һәм дини яктан тикшерелде.

Чара Коръән аятьләре уку белән башланып китте. Аннары Татарстан мөселманнары Дания нәзарәтенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов "түгәрәк өстәл"гә килүчеләрне сәламләп, Пәйгамбәребезнең (сгв) сыйфатлары турында сөйләде.

"Түгәрәк өстәл" сөйләшүен алып барган Рөстәм хәзрәт Батыр Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) дөньяга килүе - кешелек дөньясы өчен зур әһәмияткә ия, дип билгеләп узды. "Чыннан да, Пәйгамбәр (сгв) туу - кешелек тарихында зур вакыйга, чөнки, дин белгечләре язганча, шуның белән дөньяның балачак дәвере тәмамлана. Хәзер без кулыбызга Коръән алып, аңыбызда булган хәлдә тормышыбызны ничек коруыбыз өчен үзебез җаваплы. Пәйгамбәрләр миссиясе тәгәлләнде, берәү дә безгә ничек яшәргә кирәк икәнлеген әйтеп-өйрәтеп тормаячак. Пәйгамбәребез (сгв) дөньяга килгәннән соң кешелек дөньясы үсеш алды. Менә шуннан чыгып караганда, без дөньякүләм яңа этапка аяк бастык. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) - бу дөньяны яхшы якка үзгәрткән шәхес, шуңа күрә аның белән кызыксынучылар күп", - дип билгеләп узды Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы рәисе Р.Батыр.

Дагстан мөфтие урынбасары Мөхәммәт Мөхәммәтов бүгенге көндә Мәүлид аша кешеләрне ислам диненә өндәү кирәклеген әйтте. Ул "Мәүлидне уздыру бидгатьме?" дип бәхәсләшүләрнең урынсыз булуына тукталды: "Бервакыт, машинада барганда радио тыңлап барабыз. Шунда музыкага ияреп, Мәүлид җырлары ишетелә башлауга, янымда утырган кардәшем: "Моны тыңлау - бидгать", - дип, радионы башка дулкынга күчереп куйды да, заманча җырлар тыңлауга күчте. Ә мин: "Монысы бидгать түгелме?" - дип сорадым. Менә шундый хәлләр дә бар бездә. Пәйгамбәребезне (сгв) олылау - ул Ислам өчен зарар китерә торган яңалык була алмый". Мөхәммәт хәзрәт, Камал театрында узган Мәүлид бәйрәменең хатын-кызлар өчен аерүча мөһим булуы турында билгеләп узды, дагстанлыларның да бу бәйрәмгә чакыру алганы өчен

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### "ДУМ РТ ХАДЖ"НЫҢ РӘСМИ САЙТЫ АЧЫЛДЫ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хаж операторы "ДУМ РТ Хадж"ның рәсми сайты эшли башлады (www.dumrt-haj.ru).** Сайтта хаж кылу тәртибе һәм "ДУМ РТ Хадж" тәкъдим иткән программалар турында мәгълүматлар урын алган. Изге сәфәргә җыенучылар өчен сайт аша элемтәгә керү мөмкинлеге дә каралган. Шулай ук хаҗга кагылышлы соңгы хәбәрләр белән танышырга, барлык мөселманнар өчен изге саналган урыннарга багышланган язмаларны укырга мөмкин.

### ДМИТРИЙ МЕДВЕДЕВ МӨФТИ ИЛДУС ХӘЗРӘТ ФӘИЗНЕ ЮБИЛЕЕ БЕЛӘН КОТЛАДЫ

**Россия Премьер-министры Дмитрий Медведев Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәизне 50 яшьлек юбилее белән котлады.**

"Сезне абруйлы дин эшлеклесе, традицион ислам кыйммәтләрен актив яклаучы буларак беләләр. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте җитәкчесе вазифасында хезмәт куюыгыз, кыюлык күрсәтүегез һәм югары дәрәҗәдә гражданлык җаваплылыгы дин вәкилләре арасында гына түгел, ә киң җәмәгатьчелек даирәсендә дә хөрмәт уята. Сезнең яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бирү, конфессияара һәм милләтара диалог үсеше өчен күп көч һәм күп вакыт бирүегез зур әһәмияткә ия", - диелә котлау телеграммасында.

### МӨФТИ ИЛДУС ХӘЗРӘТ ФӘИЗ ТӨРКИЯ КОНСУЛЫ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

**30 гыйнвар көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә мөфти Илдус хәзрәт Фәиз Төркиянең Казандагы генераль консулы Сабри Тунч Ангылы белән очрашты**. Очрашуда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов һәм Татарстан мөфтиятенең халыкара элемтәләр бүлеге җитәкчесе Хәбибулла хәзрәт Нәфисуллин катнашты.

### НУРЛАТ РАЙОНЫНДА КЫРЫК БЕРЕНЧЕ МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ

**Нурлат районының Түбән Нурлат авылында яңа мәчет ачылды.** Мәчет ачылышында район башлыгы Наил Шарапов, Аксубай, Чирмешән районнарыннан килгән имамнар һ. б. бик күп мәртәбәле кунаклар катнашты. Минсалих дип исем бирелгән әлеге мәчетне Түбән Нурлатта туып үскән, хәзер Чаллы шәһәрендә яшәүче якташлары Рәмис Таҗиев төзеткән.

# ВӘГЪДӘДӘ ТОРУ – ИМАННАН

***"Әй, иман китергәннәр, антыгызда (вәгъдәгездә) торыгыз..."***

**("Маидә (Табын)" сүрәсенең 1 нче аяте).**

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә әлеге аятьтә безгә "вәгъдәләрегездә торыгыз" дип боера. Вәгъдәдә тору, әйткән сүзеңне үтәү - кеше өчен дөньяда да, ахирәттә дә зур әһәмияткә ия. Галимнәр вәгъдәне өч төргә бүлеп карыйлар:

беренчесе - Аллаһы Тәгалә һәркемнән Коръән белән гамәл кылырсыз дип вәгъдә алды;

икенчесе - Аллаһ исеме белән әйткән антлар;

өченчесе - мөэминнәрнең үзара куешкан антлары.

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә җаннарны яраткач Үзен танулары турында вәгъдә ала. Аллаһы Тәгәлә Коръәни-Кәримдә болай ди: "Кыямәт көнендә:

- Без моннан хәбәрсез идек, - дип әйтмәсеннәр өчен, Раббың адәм балаларыннан, аларның тәненнән токымнарын чыгарды, аларны үзенә шаһит итте вә әйтте:

- Мин сезнең Раббыгыз түгелмени? - диде. Алар да:

- Әлбәттә, шаһит булдык *(син безнең Раббыбыз)*, - диделәр". ("Әгъраф (Пәрдә, калкулык)" сүрәсенең 172 нче аяте).

Димәк, безнең барыбызның да җаннарыбыз Аллаһы Тәгаләне таныган, шул танулары турында ант иткән һәм бу хакта онытканнарга Коръән белән исләренә төшерелгән. Безнең барыбызның да җаннары Аллаһы Тәгаләне танулары турында ант итүләре сәбәпле һәр бала фитри иман белән дөньяга килә. Бу хакта пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) болай ди:

مَا مِنْ مَوْلُودٍ إِلاَّ يُولَدُ عَلَى الفِطْرَةِ ، فَأَبَوَاهُ يُهَوِّدَانِهِ أَوْ يُنَصِّرَانِهِ أَوْ يُمَجِّسَانِهِ

*"Һәр бала фитри иман белән, ягъни Аллаһы Тәгаләнең берлегенә ышаныч белән туа. Аны фәкать ата-аналары гына яһүди, насара яисә мәҗүси итеп тәрбияли" (Бохари, 1358).*

Бүген бик күпләр Аллаһы Тәгаләгә биргән вәгъдәләрен үтәми. Ата-ананы. динсез тәрбиясе нәтиҗәсендә бала иманыннан яза, Раббысын оныта. Хәтта адәм баласы Аллаһы Тәгаләне таныган хәлдә дөньяны яратудан туктамый, Коръән белән гамәл кылмый.

Вәгъдәнең икенче төре булып Аллаһы Тәгаләнең исеме белән әйтелгән антлар, нәзерләр тора. Кеше авыр хәлгә юлыкса Аллаһы Тәгаләнең исеме белән төрле антлар, нәзерләр әйтергә ашыга, нәзерләренең дөресме-түгелме, үти алырлыкмы-юкмы икәнлеге турында уйлап та карамый. Уйламыйча әйтелгән нәзерләр белән үзен күпме гөнаһка алып бара.

Галимнәр нәзерне берничә төргә бүлеп карый:

1. Максат итеп аерым бер гыйбадәт белән нәзер әйтү. Мәсәлән, ике рәкәгать намаз укуны, бер көн ураза тотуны, күпмедер күләмдә сәдака бирүне.

2. Гыйбадәткә сәбәп булган нәрсә белән нәзер әйтү. Мәсәлән, тәһарәт алу, хаҗга җәяү бару, мәчет салу.

3. Гыйбадәт түгел нәрсә белән нәзер әйтү. Мәсәлән, кояш кызуында тору, ит ашамау.

4. Хәрам нәрсәләр белән нәзер әйтү. Мәсәлән, хәмер эчү.

Монда санап кителгәннәрнең фәкать беренчесе генә әйтелә ала, калганнарын әйтү ярамый. Шушылар арасында рөхсәт ителгәннәреннән киң таралганына мисал итеп сәдака бирү яисә корбан чалуны, ә тыелганнарының киң таралганыннан хәрам куллануны китерә алабыз. Мәсәлән, "Әгәр терелсәм (яисә нинди дә булса уку йортына керсәм), рестoранга алып барып иң яхшы коньяклар белән сыйлар идем", - дип әйтү. Рөхсәт ителгәне үтәлә, ә тыелган нәзер белән нишләргә?

Пәйгамбәребез (сгв) әйткән:

مَنْ نَذَرَ أَنْ يُطِيعَ اللَّهَ فَلْيُطِعْهُ ، وَمَنْ نَذَرَ أَنْ يَعْصِيَهُ فَلاَ يَعْصِهِ

*"Бер кеше Аллаһка итагать итү белән нәзер әйтсә, шул нәзерен үтәсен, вә бер кеше Аллаһы Тәгаләгә гөнаһ эш белән нәзер әйтсә, гөнаһ эшләмәсен" (Бохари, 6700).*

"Наданлык белән, белмәү сәбәпле әйтелгән нәзерләрне, бирелгән вәгъдәләрне үтәргәме-юкмы?" - дигән сорауга бу хәдис-шәриф җавап булып тора.

Шәригать буенча, әйтелгән нәзер үтәлмәгән очракта, нәзер әйтүче бер колны азат итәргә, әгәр дә кол азат итә алмаса, ун фәкыйрьне ашатырга яисә киендерергә, ә инде анысын да булдыра алмаса, өч көн ураза тотарга тиеш.

Алда әйтеп кителгән өч төр вәгъдәнең ике төре Аллаһы Тәгаләнең исеме белән бәйле һәм Кыямәт көнендә адәм баласының Раббысы каршында аерым җавап бирә торганнары. Дөньялыкта бер-беребезнең дәрәҗәсен төшерүгә, бер-беребезне кимсетүгә сәбәп булмасалар да, ахыр чиктә динебезнең бидгатькә батуына, бетүенә сәбәп була торганнары.



Ә инде кешеләр арасында мөселманнарга карата уңай яисә тискәре караш уятуга, ислам дине таралуга яисә бетүгә сәбәп була торганнары - ул мөэминнәрнең үз араларында була торган, сүз куешкандагы вәгъдәләре. Кешенең вәгъдәсендә торуына карап аның турында башкалар фикер йөртә. Шуңа күрә мөселманнарның вәгъдәләрендә торулары ислам дине таралсын өчен аеруча зур әһәмияткә ия. Вәгъдә биреп тә, аны үтәми йөрү - дин кардәшләребезнең Исламга тап төшерүе ул. Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: "Әгәр дә инде алар сезне тоткын итсә, дошманлык кылсалар, куллары һәм телләре белән сезне рәнҗетеп, *(Аллаһны инкарь итеп, динегездән)* ваз кичтерсәләр, Кыямәт көнендә якын кардәшләрегез дә, балаларыгыз да сезгә файда итә алмас. Аллаһ сезне алардан *(якыннарыгыздан)* аерыр. Аллаһ бөтен гамәлләрегезне күреп тора *("Мүмтәхинә (Хатын-кызны сынау)" сүрәсенең 2-3 нче аятьләре)*.

Вәгъдә биреп, аны үтәмичә йөрү, әлбәттә, зур гөнаһ. Күпләр өчен Ислам, мөселман дигән сүзләр маяк, ышаныч чыганагы булып тора. Кеше шушы сүзне әйтүчеләргә "мин мөселман" дигәне өчен дә ышана. Шуңа күрә "мин мөселман" дип әйтелгән антлар, вәгъдәләр, әгәр дә үтәлә икән, халкыбызның ислам диненә тартылуына сәбәп булырга мөмкин, әгәр дә үтәлми икән, киресенчә, халкыбызның ислам диненнән читләшүенә сәбәп булырга мөмкин. "Мәчет-мәдрәсәләргә ярдәм итәбез", - дип вәгъдә бирүчеләрне күп күрергә туры килә, шуларга ышанып төзелешләр башлыйсың, әмма эшкә терәлгәч, сүз вәгъдәдән ерак китми. Инде бик дини булып кыланганнары: "Аллаһ насыйп итмәде", - диләр...

Берәү үзен мөселман санап та, намазлар укып та гамәлләре белән вәгъдәсезлектә кала икән, Аллаһ сакласын, ул кеше монафикълардан саналыр. Хәзер муллаларга бәяне түрәләрдән сорый белгәнгә карап бирәләр. Үзара сөйләшкәндә дә "сорый белсәң, бирәләр" дигән гыйбәрә йөри. Бу хакта пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән:

إِنَّا نَدْخُلُ عَلَى سَلاَطِينِنَا فَنَقُولُ لَهُمْ بِخِلاَفِ مَا نَتَكَلَّمُ إِذَا خَرَجْنَا مِنْ عِنْدِهِمْ.قَالَ: كُنَّا نَعُدُّ هَذَا نِفَاقاً عَلَى عَهْدِ رسُولِ الله صلى الله عليه وسلم

*Мөхәммәд ибне Зәйддән риваять кылына. Кешеләр Габдулла ибне Гомәргә (рг) әйттеләр: "Без солтаннарыбыз янына керәбез һәм алар каршында бер нәрсә, чыккач икенче нәрсә сөйлибез". Габдулла ибне Гомәр әйтте: "Пәйгамбәребез (сгв) вакытында бу нәрсәне "монафикълык" дип атый идек", - диде ("Изгеләр бакчасы" китабы, 259 б.).*

Дөньяның аз малына алданып, вәгъдәбезнең үтәлмәячәген белә торып ялган вәгъдәләр бирергә ашыкмасак иде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән:

آيَةُ الْمُنَافِقِ ثَلاَثٌ إِذَا حَدَّثَ كَذَبَ ، وَإِذَا وَعَدَ أَخْلَفَ ، وَإِذَا اؤْتُمِنَ خَانَ

*"Монафикълыкның билгесе өчтер: сөйләсә - ялганлый, вәгъдә бирсә - вәгъдәсен боза, үзенә ышанып тапшырылганга хыянәт итә" (Бохари, 6095).*

Икенче бер хәдистә исә: "Хәтта ул мөселман булган хәлдә ураза тотса, намаз укыса да", - дип әйтелә. Без, әлбәттә, кешенең гамәл-гыйбадәт кылуына карап аның турында фикер йөртәбез. Әмма, әлеге хәдистән күренгәнчә, кешене гамәл-гыйбадәт кенә мөселман итми. Фарыз гамәлләрне үтәү, әлбәттә, кирәк, ул - мәҗбүри, әмма иң мөһиме - күңел пакьлеге. Чын күңелең белән ислам динен кабул иткәндә генә ялганга, вәгъдәсезлеккә һәм башка тискәре сыйфатларга урын калмый.

Вәгазебездә әйтелгәннәрдән чыгып, һич кенә дә "вәгъдә бирергә ярамый" дип нәтиҗә ясарга кирәкми. Киресенчә, вәгъдә бирүдә һәм аны үтәүдә бер-беребез белән ярышырга кирәк. Бүген динебез ничә дистә еллардан соң күтәрелеп кенә килә, хәтта үзен "мин мөселман" дип санаучылар да күп түгел. Инде шушы көннәрдә дә бер-беребезгә мөмкинчелек була торып ярдәм итешмәсәк, вәгъдәләр бирешмәсәк, килешү юлына басмасак һәм биргән вәгъдәләребезне үтәргә ашыкмасак, без ничек бер өммәт булып оешачакбыз ди инде?!

Пәйгамбәребез (сгв) үтенеч белән килгән бөтен кешенең дә үтенечен үтәргә, шул ук вакытта, үти алмаса да, үтәргә вәгъдә бирергә тырышкан һәм, никадәр генә авыр булса да, биргән вәгъдәсен үтәгән.

Милади ел исәбе буенча 628 елда Мәккә мөшрикләре белән Мәдинә мөселманнары арасында Ходайбия янында бер килешү төзелә. Бу килешү буенча мөселманнар ягына күчкәннәрне кайтарып бирүнең мәҗбүрилеге, ә мөселманнар ягыннан күчкән корәешлыларны кайтарып бирүнең мәҗбүр түгеллеге карала. Мөселманнар арасында зур ризасызлык тудыруга да карамастан, бу килешү төзелә, ике данәдә языла һәм ике якка да тапшырыла. Бу вакытта мөшрикләрнең башлыгы Сүхәел бин Әмир мөселман булган улы Әбу Җәндәлне, Мәккәдән Мәдинәгә качмасын өчен, кул-аякларын чылбырлар белән бәйләп зинданга япкан була. Шуңа да карамастан, Әбу Җәндәл, юл табып, Мәккәдән качып Мәдинә мөселманнары янына килә.

Сүхәел бин Әмир, улы Әбу Җәндәлне күргәч, Пәйгамбәребезгә (сгв): "Минем белән төзелгән килешүгә таянып синнән, иң әүвәл, улымны сорыйм. Аны безгә кире бир", - дигән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) үзенең вәгъдәсендә торып, Әбу Җәндәлне кире кайтарган. Хәтта Әбу Җәндәл: "Мәккәлеләр динебез өчен дошман, мине дошман кулына калдырмагыз", - дип ялварса да. Пәйгамбәребез (сгв): "Сабыр ит, Әбу Җәндәл! Аллаһтан өметеңне өзмә. Аллаһы Тәгалә тиз арада сиңа һәм синең кебек мөселманнарга бер чарасын табар", - дип, вәгъдәсендә калган.

Бүгенге көндә без үзебезне мөселманнар дип саныйбыз икән, без башкаларга үрнәк булырга тиешбез. Башка кешене яхшылыкка өндәүдән элек, үзебезне тәрбияләргә кирәк. Бу турыда безгә Коръәни-Кәрим һәм Пәйгамбәребез (сгв): "Вәгъдәдә тору - иманнан", - ди. Иманлы бәндәләрдән булсак, биргән вәгъдәләребезне бозмасак иде.

Бирелгән вәгъдә мөһим булган берәр сәбәп аркасында үтәлми калса, вакытында сәбәбен аңлатып, ул кешедән гафу үтенү дә дөрес булыр. Дөнья малына алданып ялган антлар бирмәсәк иде. Кыямәт көне турында онытмыйк, ул Көндә сорау каты булачак. Аллаһы Тәгаләгә биргән антларыбыздан да, Аллаһы Тәгалә исеме белән бирелгән антларыбыздан да, нәзерләребездән дә, үзара куешкан вәгъдә килешүләребездән дә соралачакбыз.

Аллһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә болай ди: "Балигъ булганчыга чаклы (сезнең карамактагы) ятимнәр малына, (шул малны арттыру ниятеннән тыш) якын килмәгез. Антыгызны (ятим каршындагы вазифагызны) җиренә җиткезеп үтәгез. Антыгыз өчен җавап тотасыгыз бар" ("Исра (Төнге йөрү, Ягъкуб угыллары)" сүрәсенең 34 нче аяте).

Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә беребезне дә ким-хур булучылардан насыйп кылмаса иде.

***Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ,***
***Татарстанның Кама буе төбәге казые,***
***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең***
***Голамәләр шурасы әгъзасы,***
***Чаллыдагы Ак мәчет мәдрәсәсе директоры***

# Мәүлид галимнәрне "түгәрәк өстәл"гә җыйды

***(Дәвамы. Башы 1 нче биттә.)***

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә рәхмәтен җиткерде. "Театрда үткән чарада халык берьюлы бик күп хәзрәтләрнең вәгазьләрен тыңлый алды", - дип тә өстәде ул.

РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин үзенең чыгышында дини йолаларыбызга якыная башлавыбыз хөрмәтенә шатлануын белдерде. "Без үзебезнең традицияләребезне сакларга тиеш, алардан башка дин оешмый бит. Без моны дөрес аңларга тиеш. Мәүлид бәйрәме дә - ул безнең күпгасырлык традиция", - диде Р.Мөхәммәтшин. Казан (Идел буе) федераль университетындагы Филология һәм сәнгать институтының татар әдәбияты тарихы кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы, язучы Фәрит Яхин бабаларыбызның Мәүлидне ничек итеп үткәрүләре турында бөртекләп сөйләде. Россия Фәннәр академиясендәге Шәркый кульъязмалар институтының (Санкт-Петербург) өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Алексей Хисмәтулин; чыгышы белән кырым татары, Ислам цивилизациясе институты (Мәскәү) директоры, ИСЕСКО Югары Советы әгъзасы һәм аның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле Сәет Кямилев; Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының этнология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Рәүфә Уразманова, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы һәм исламны өйрәнү бүлеге мөдире, тарих фәннәре кандидаты Дамир Шәһабиев һәм башкаларның чыгышлары "түгәрәк өстәл"дә катнашучыларда зур тәэсир уятты.

Дин белгечләре, Исламны өйрәнүче галимнәр мондый сөйләшүләрнең мөһимлеген һәм билгеле бер мәсьәләләргә фәнни, тарихи яктан ачыклык кертү зарурлыгын билгеләп узды.

**Чыганак: www.dumrt.ru**

# Төрки-болгар-татарларның экстремизм идеологиясен кисәтү буенча тарихи тәҗрибәсе

**Россия дәүләте барлыкка килү процессындагы көнүзәк мәсьәләләрне караган вакытта, без еш кына тарихи үткәнебезгә мөрәҗәгать итәбез. Күпмилләтле һәм күпконфициональ Россия өчен андый проблемаларның берсе - үзара тыныч юл белән милли һәм дини мөнәсәбәтләрне саклау.**

Борынгы заманнардан башлап бүгенге көнгә кадәр Россия территориясендә, славяннар күчеп килгәнгә кадәр күп еллар элек үк, күп кенә халыклар, кабиләләр яшәгән. Һун державасы, Борынгы Төрки, Кимәк, Уйгыр, Хәзәр каганлыклары һәм башка дәүләтләрнең тарихы шул җирләрдә үткән. Димәк, киләчәк Россия дәүләтенең күпмилләтле булуы - тарихның үзе тарафыннан билгеләнгән. Ә күпмилләтле Борынгы Русь дәүләте Хәзәр каганлыгы, Кыпчак ханлыклары, һәм дә, әлбәттә, Идел Болгарстаны, Алтын Урда һәм ул таркалгач барлыкка килгән башка татар ханлыклары белән янәшә, күрше булып яшәгән. Боларның барысын да без беләбез. Ләкин еш кына, хәтта рәсми дәреслекләрдә дә бу фактларга игътибар аз бирелә яки алар хакында бөтенләй сүз алып барылмый. Борынгы һәм Мәскәү Русе тарихындагы күп кенә бәрелешләр хакында языла, күп вакыт алар кара буяулар белән тасвир ителә. Күпкырлы үзара тыныч мөнәсәбәтләр, шул исәптән дини бәйләнешләргә... багланышларга да урын аз бирелә. Ә бит алар бүгенге көн өчен сабак була алалар. Борынгы һәм урта гасырлар Россиясендә дини сугышлар булмаган дип әйтерлек. Өлешчә, татар ханлыкларын яулап алулар хакында гына сүз алып барып була. Ләкин аларны да "чиста" дини сугышлар дип атап булмый.

Күпмилләтле төрки-татар (күп кенә тарихчылар тарафыннан, шул исәптән инкыйлабка кадәр үк кулланылган шартлы термин) җәмгыятьләренең характерлы үзенчәлеге - аларның бар диннәргә дә сабыр караштa булулары. Борынгы төрки каганлыклар вакытында ук рәсми тәңречелек дине белән бергә буддизм, брахманчылык, мани дине (манихейлык), Борынгы Кытай диннәре таралыш алган булган. Хәзәр каганлыгында да ислам, православие, яһүд диннәре, тәңречелек үзара тыныч яшәгәннәр.

Идел Болгарстанында, ислам рәсми дин буларак кабул ителгән булса да, христиан, аннан соң Әрмән бистәсенә дә урын табылган. Мәсәлән, Биләрдә безгә рус гәрәбәче-зәргәрчесенең кярханәсен (мастерской. - ред.) өйрәнергә туры килде. Ул башкаланың үзәгендә үк урнашкан булган. Анда Владимир Олы Ояның (Владимир Большое Гнездо) асылмалы мөһере табылды. Бары тик бу йортта гына дуңгыз сөякләренең калдыклары бар иде. Болгарда, христиан бистәсеннән тыш, үзенең чиркәве белән Әрмән бистәсе дә булган. Галимнәр аны, ни өчендер, шартлы рәвештә "Грек пулаты" дип атыйлар. Әрмән зиратында әрмән телендә, әрмән графикасы белән язылган каберташлар бүгенге көндә дә бар. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, ташлардагы текстларда болгар сүзләре дә кулланылган. Әрмәннәр монда килеп монгол яуларыннан сыену урыны тапканнар. Казан ханлыгы чорында да хәзерге Сукно бистәсе урынында Әрмән бистәсе булган.

Озакламый Алтын Урда төрки-татар дәүләтенә әйләнә. Бу төркиләр, нигездә, болгарлар һәм кыпчаклардан торган. Алтын Урдада ислам дәүләт дине буларак кабул ителсә дә, анда башка диннәргә дә - православие, католицизм, буддизм, мәҗүсилеккә дә урын табыла. Бу илнең башкаласы Сарай әл-Җәдидтә 13 җәмигъ мәчете, 5 православ чиркәве, католик костелы, будда гыйбадәтханәсе һ. б. дини



йолалар үтәү йортлары була. Православие метрополиясе эшләп килә. Алтын Урданың күп кенә шәһәрләрендә - Кырымдагы, Кара диңгез буендагы, Төньяк Кавказ шәһәрләрендә мөселманнар белән бергә православлар, ә хәзерге Саратов шәһәре янында урнашкан Үкәк шәһәрендә католиклар тормыш кичергән. Башка диннәргә карата андый сабыр мөнәсәбәт Урта гасырларның башка илләрендә булганмы икән? Алтын Урдада барлык дини руханилар да салымнардан азат ителгән. Дәүләт ханы Мөхәммәд Үзбәк фәрманы буенча, православ руханиларга карата әйтелгән бер начар сүз өчен генә дә - җирле халык вәкилләре - мөселманнар үлем җәзасына тартылган.

Мөселман мәгарифенең икенче баскычы булып, Шәрыкның фәнни һәм мәдәни үзәкләрендә - Бохарада, Сәмәркандта, Нишабурда, Бәлхта, Багдадта, Мәрвтә, Газнәдә белем алу тора. Монда укып чыккан болгарлар ул вакытлар фәне, Шәрык мәдәнияте казанышлары белән турыдан-туры танышалар. Күп кенә галимнәр бу Шәрык мәдрәсәләренең атаклы гыйлем ияләре кул астында махсус белемнәр ала.

Бу дәвердә бар ислам дөньясында да "укытучы-укучы" (дин гыйлемендә - "мөршид-мөрид". - Г.Д.) институты киң таралыш алган. Никадәр тирән белемнәргә ия булуың - укытучың кем булуында. Атаклы, югары квалификацияле укытучы-остаз эзләп гыйлем алучылар бик күп илләрне гизгән. Алар үзләре укыган укытучыларның исемнәрен һәм титулларын зур ихтирам һәм горурлык белән искә алган. Танышканда да, горурланып: "Мин фәлән остазның шәкерте булам", - дигәннәр. Укытучылар да үзләренең талантлы укучылары белән горурланган. Мөгаллимлек эше, остазлык еш кына нәселдән-нәселгә - атаданулга тапшырылып барган.

Мөселман мәгарифе һәм педагогикасында бөек китап Коръән үзе булган. Идел Болгарстанында шулай ук тирән әхлак һәм тәрбия корылмасы йөртә торган мөселман илаһияте фәне дә нык үсеш алган.

Болгар җәмгыятендә төрле фәннәргә зур әһәмият бирелгән. Мондый хөрмәт белән карауның нигезендә ислам тәгълиматы ята. Коръәндә "гыйлем, голамә" сүзләре һәм аннан чыгышлы башка сүзләрнең 750 тапкыр очравын санап чыгарганнар. Үз сөйләмендә бу сүзләрне Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) дә бик еш кулланган. Гыйлемлелек, укымышлылык, белемгә омтылу - һәр мөселманның изге бурычы дип игълан ителгән. Әлбәттә, бу очракта дини гыйлем бирү дә, дөньяви гыйлем бирү дә күз алдында тотыла. Төгәлрәк әйткәндә, ул вакытларда алар арасында әллә ни аерма күрмәгәннәр һәм алар бер-берсенә каршы куелмаган.

Әдәби әсәрләр дә тәрбия-педагогиканың, дини/дөньяви/фәнни белемнәрнең, мораль-этик нормалар таралуның тәэсирле чарасы булган. Төрки-татар җәмгыятьләрендә яшьләр туган җиргә, ата-бабага, аларның мирасына, өлкәннәргә карата мәхәббәт һәм ихтирам рухында тәрбияләнә. Болгар җәмгыятендә аеруча зур хөрмәт өлкәннәргә булган. Ибне Фадлан: "... (кемнең дә булса бер) кешенең баласы туса, "Аның әтисе җитлеккән ир булмыйча торып, баланы тәрбияләү өчен минем хокукларым күбрәк", - дип, ул баланы аның бабасы (үзенә) тәрбиягә ала". "Картлар сүзен ишеткәндә, бүркеңне куеныңа куй", - диелә татар мәкалендә. Бу мәкаль болгарларда киң таралган булса кирәк, чөнки анда, болгарларның, аеруча ихтирамга лаек кеше белән очрашкан вакытта, бүрекне салып, култык астына кую гадәте чагылыш тапкан. XII гасырда яшәгән Урта Азия галиме, шагыйрь, фикер иясе Йосыф Баласагунлының "Котадгу белег"е ("Бәхетле булу белеме") мораль-этик һәм әхлакый идеаллар белән сугарылган. "Котадгу белек" - үз заманының үзенчәлекле әхлак кодексы. Бәхетле булу - ул гыйлемле, тәрбияле булу дигән сүз. Автор үзенең даһи әсәрен шул мәгънәдә атаган да.

Борын-борыннан нинди асыл сыйфатлар алга сөрелгән соң? Кол Гали фикеренчә, камил кешегә түбәндәге сыйфатлар хас:

Беренчедән, буе зифа, чибәр үзе,
Икенчедән, якты чырай, күркәм йөзе,
Өченчедән, теле төзек, туры сүзе,
Җитмеш ике телне тәмам белә имди.
Дүртенчедән, алып йөрәкле һәм гайрәтле,
Алтынчыдан, күп кешедән ул куәтле,
Кырык ирдән куәте аның артык имди.
Бишенчедән, дине бөтен, диниятле,
Сигезенче, хаин түгел, әманәтле,
Тугызынчыдан, холкы йомшак, теле татлы,
Унынчыдан, пәйгамбәрләр нәсле имди.

Казан ханлыгында да мөселман мәгарифе һәм педагогикасы буенча бөек китап булып Коръән исәпләнә. Хафиз мөгаллимнәр Коръәнне дөрес итеп, яттан сөйләргә өйрәткәннәр. Казан мәгърифәтчеләре әлеге Изге Китапка үз тәфсирләрен дә язганнар. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәреннән 1508 елда язылган "Коръән тәфсире" китабы һәм 1508 елда Мөхәммәд Әмин вакытында төзелгән "Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) хәдисләре" дип аталган җыентык бар.

Казан ханлыгы чорында мәгърифәт эшчәнлеген дин әһелләре алып барган. Мәчете булмаган бер мөселман авылы да күзәтелмәгән. Ә һәр мәчеттә мәктәпмәдрәсә эшләгән. Бар кеше дә укыргаязарга өйрәнгән, белемгә тартылган. Дин әһелләре дә мөгаллимлек эше белән шөгыльләнгән, эш кәгазьләрен төзи белүчеләрне, каллиграфик юл белән китап күчерүчеләрне, ясак җыючыларны, галимнәрне, шагыйрьләрне дә алар әзерләгән. Казан ханлыгының зыялы кешеләре, гадәттә, берничә тел белгән. "Татарга тылмач кирәкми" дигән әйтем шул чорларда урнашып калган булса кирәк. Казан ханлыгы кешеләренең югары мәдәниятлелеген, укымышлылыгын ул вакытларда ханлыкта булып киткән чит ил вәкилләре дә билгеләп үтә. Австрия илчесе Сигизмунд Герберштейн үз сәяхәтнамәләрендә: "Бу татарлар башкаларга караганда алга киткәнрәк, укымышлырак, алар җир эшкәртәләр, өйләрдә яшиләр һәм төрле сәүдә эшләре белән шөгыльләнәләр", - дип язып калдырган.

"Укытучы - укучы" институты бу дәвердә дә яшәвен дәвам иттерә. Мөгаллимлек, остазлык еш кына нәселдәннәселгә күчеп бара. Мәсәлән, Биектау районындагы Тимерче авылында табылган кабер ташында: "Миргали мөгаллимнең улы Шаһимәрдән мөгаллим 1534 елны вафат", - дип язылган. Казан ханлыгы чорында Болгар шәһәре (Шәһре Болгар) хәрабәләрдә яткан. Шуңа да карамастан, ул Казан ханлыгы мөселманнарының дини-агарту үзәгенә әйләнә. Болгар археологлары билгеләве буенча, "мөселманнарның изге урыннары (Болгар шәһәре. - Г.Д.) янында сакланып калган хәрабәләрне кадерләп торучы диндар кешеләр булган". Кече манара янындагы каберләргә зиярәт кылучылар аеруча күп булган. Анда Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) сәхабәсе Әхтәм, изге Балым хаҗи, изге кыз җирләнгән дип уйлаганнар. Шундый мактаулы эш белән Казан ханлыгының бөек шагыйре Мөхммәдьяр да шөгыльләнгән, ул Мөхәммәд Әмин төрбәсенең мөҗәвире (карап торучы, сакчы, мәрхүм хакында хәбәр бирүче) хезмәтен үтәгән. Болгар шәһәреннән тыш, изге урыннарны шул рәвешле саклап торуны XVIII гасыр сәяхәтчесе Н.П. Рычков Биләр шәһәре янындагы Балынгуз тавында да очраткан. Анда борынгы мәчет калдыклары, төрбәләр, ташъязмалы каберләр булган. Җимерелгән шәһәрләргә һәм андагы каберләргә татар халкы зур ихтирам күрсәткән. Аларга барып зиярәт кылу - саваплы эш булып исәпләнгән һәм ата-бабаларыбызның тарихына һәм батырлыгына тиешле хөрмәт күрсәтү булып саналган. Болар барысы да милли үзаң, милли горурлык хисләрен саклап калуда, аны үстерүдә һәм, гомумән, халыкны милләт буларак саклап калуда гаять зур роль уйнаган. Татар халкының рухи тарихында әле дә булса суфиларның роле тиешле бәясен алмаган. Безнең якларда суфилар исеме белән бәйле андый урыннар аз түгел. Алар, чынлап та, халкыбыз тарихының караңгы чорлары - XVI гасырның икенче яртысыннан башлап һәм XVII-XVIII гасырларда татар рухи тормышында алыштыргысыз, бәяләп бетергесез зур роль башкарганнар.






Өлкәннәрне ихтирам итү, вафат булганнарга хөрмәт белән карау - төрки-татарлар өчен борын-борыннан ук табигый күренеш. Болгар-татар кабер ташларындагы язмаларның бик борынгы заманнардан ук юл алган тирән тамырлары бар. Кабер ташларына текстлар язу мәдәнияте Болгар чорларыннан Казан ханлыгына да күчкән. Алар сәнгатьчә эшләнелешләренең югары формада булуы белән аерылып тора, аларның күбесенә вафат булучы белән мәңгелеккә аерылышырга туры килгән кешеләрнең зур кайгысы

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

## Адлер ТИМЕРГАЛИН:

# "ӘГӘР КАЛЬБЕҢДӘ АЛЛАҺ ЮК ИКӘН, СИНДӘ ӘХЛАК ТА ЮК!"

**Адлер абыйның вафаты турында интернет сайтларыннан укып белдем.**



Бичара, дистә еллар буе астмадан иза чикте. Телефоннан чылтыратканда да карлыккан тавышы белән бик авырдан сөйләшә иде. "Хачману" суыкларында бу хәтәр чир отыры көчәя иде. Өенә барып интервью алганда да ул әледән-әле ислемай флаконы сыман бер әйберне авызына якын китереп, "пышт" итеп бер йотым даруны сиптереп ала һәм әңгәмәбез дәвам итә.

Энциклопедик белемле, риясыз, сабыр холыклы бу шәхес, байтак кына каләмдәшләреннән аермалы буларак, искиткеч тыйнаклыгы белән аерылып торды. Ул беркайчан да мактаулы исемнәр, дәрәҗәле урыннар, мал-байлык, дан-шөһрәт артыннан кумады. Бу хакта кызыксынгач, ул бервакыт:

- Миңа бөртекләп җыйган рухи байлыгым житә, - дип, үзенең яшәү кагыйдәсен белдерде.

Адлер ага китап җене кагылган зат иде. Аның Рихард Зорге урамындагы "хрущевка"сы идәннән алып түшәмгә кадәр шыплап китап белән тулган иде. "Минем иң яратканым - китап", - дип әйткәне исемдә.

Язмыш аның башыннан гел сыйпап тормаган. Балачагы авыр сугыш елларына туры килгән. Ләкин бу михнәтләр чәчәге генә икән әле. Тагы да катлаулы сынаулар егетне студент елларында көткән. Ул япа-ялгызы тоталитар системага каршы көрәшкә чыга. "Халыклар атасы"ның шәхесне, милләтне изү сәясәтенә ризасызлык белдерә торган листовкалар таратырга тотына. Җил тегермәннәре белән сугышып йөргән "дон-кихот"ны "череккүлчеләр", әлбәттә, бик тиз исәплә чыгара һәм кулга ала. Социаль һәм милли гаделлекне торгызу юлына баскан беркатлы "подпольщик"ны ГУЛАГ лагерена яки төрмәгә олактырмый, МГБның Арча кырындагы яшерен зинданына гамәлдәге режим өчен иң хәтәр кешеләр - бәйсез карашлы, нык рухлы галимнәр, дәүләт житәкчеләре, шул җөмләдән Эстониянең беренче Президенты К.Пятс (1874-1956) утырган ябык төрмәгә бикләп куялар. Әмма белемгә сусаган татар баласы тоткынлыкта да югалып калмый, шундагы галимнәрдән күңеленә хуш килгән математика, астрономия, физика, химия, биология фәннәреннән, чит телләрдән сабак ала, үзен бимазалаган күпсанлы сорауларга җавап эзли, гыйлем туплый. Менә каян килгән аңа килочәктә иҗат ителәчәк фантастик әсәрләр язу өчен мәгълүмат, белем!

Адлер ага белән дуслыгым Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә бөреләнде. Четерекле мәсьәләләр, катлаулы сораулар килеп туганда киңәш-табыш итәргә аның янына килә идем. Сабыр холыклы, искиткеч әдәпле олпат зат җайлап аңлата, үзенең фикерен әйтә, киңәшләрен бирә иде.

Соңгы елларда ул туган телебезне өйрәнүдә гаҗәеп олы хезмәт башкарды. Тулы бер фәнни институт күтәрердәй "Миллият сүзлеге" (Мәгариф. - 2007, 575 б.) төзеп, аны аерым басма итеп әзерләде. Андагы байлык, андагы мәгълүмат үзе бер энциклопедия!

Адлер Камил улы алга таба бу сүзлекнең дәвамын - халкыбызның тарихына, мәдәниятенә, гомумән, рухи дөньясына өлеш керткән шәхесләргә багышланган өлешен туплап, иҗат итү һәм үзе исән чакта нәшер итү турында хыяллана иде. Әмма бу хезмәтнең нинди этапта тукталып калуы нәмәгълүм. Аның варисларыннан - балалары, оныклары арасыннан шушы эшне ахырына җиткерүче табылса, игелекле бер хезмәт булыр, бу мәртәбәле шәхеснең якты хыялы тормышка ашырылыр иде.

Кеше китә - җыры кала, диләр. Адлер абыйның бәһаләп бетергесез фантастик повестьлары, хикәяләре, тәрҗемә иткән әдәби әсәрләре, мәктәп балалары һәм студентлар өчен мөхәррир буларак эшкәрткән дистәләгән дәреслек-белешмәлекләр, ул төзегән сүзлекләр калды. Аларны кабат бастыру, мәктәп укучысы, студент, мөгаллимнәр кулына җиткерү - безнең изге буруч. Шушы олпат шәхеснең якты истәлегенә багышлап әдәби кичәләр, конференцияләр оештыру, музейкүргәзмәләр ачу, аның исемен мәңгеләштерү - шулай ук безнең өстебездә.

Әдип үзенең бер гаять мәгънәле язмасын (Тимергалин А. Алла (фәлсәфи уйланулар) // Казан утлары. 2009. - № 2) мондый сүзләр белән тәмамлый: "Аллаһны сөюебез белән без илаһи Сәмруг кош күзгесендә үзебезне дә сөябез. Аллаһны сөю белән Аллаһтан курку арасында математик тигезлек билгесе куярга мөмкин. Әгәр кальбеңдә Алла юк икән, синдә әхлак та юк. Киресе дә дөрес. Адәми зат өчен Алла - әхлак ул".

... Быел яз көне ямьле Минзәлә елгасы буендагы Иске Минзәләбаш авылы зиратында каеннар янә яфрак ярыр. Алар язгы җәйдә моңсу гына тирбәлеп утырыр. Мазарстанның хәтфә чирәмле бер почмагында зыялы мөгаллимнәр Камил ага һәм Хатирә апаларның каберләре эргәсендә кызыл балчыклы калкулык пәйда булыр. Биредә татарның газиз бер баласы, гомере буе фидакарьләрчә әдәбият, фән үсешенә, аларны популярлаштыруга ару-талуны белмичә хезмәт иткән олы шәхес - Адлер Камил улы Тимергалинның җәсәде җирләнгән.

Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигүн! (Дәреслектә, без Аллаһтан килдек, һәм аңа кайтачакбыз.)

**Рөстәм МӘҺДИЕВ**
**Чыганак: www.islam-today.ru**

---

# Төрки-болгар-татарларның экстремизм идеологиясен кисәтү буенча тарихи тәҗрибәсе

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

урын алган шигырьләр язылган. Бу язмалар Аллаһы Тәгаләне һәм мәрхүмнәрне данлыйлар. Бу дөньяда игелекле эшләр эшләп калырга өндиләр. Алар ата-бабаларыбызга, тарихыбызга тирән ихтирам, хөрмәт белән сугарылганнар.

Бу язуларда һәм археологик табылдыкларда бәхетле кешене характерлый торган төп сыйфатлар тасвирланган. Бу җәһәттән, ташбилгеләр (кабер ташъязмаларының элекке исеме) күпкә үзенчәлекле. Ташбилгеләр, нигездә, бар болгар-татар аксөякләре каберләренә куелсалар да, алар арасында аермалыклар юк түгел. Кабер ташларында халыкның югары даирәсе вәкилләрен характерлау өчен бик бөек, атаклы, данлы, затлы нәселне күрсәтә торган, җиңелмәс, диннең һәм нәселнең горурлыгы, зәгыйфьләрнең терәге кебек эпитетлар кулланылган. Алардан түбәнрәк булган урта һәм башка катлам вәкилләренең сыйфатлары итеп: дингә тугры; галимнәр тәрбияләүче, ятим, тол ир, ярлыларга ярдәм итүче; мәчетләр төзүче; саваплы гамәлләр кылучы кебек сыйфатлар күрсәтелгән. Каберташлардагы язуларда хатын-кызларга хас тыйнаклык, гыйффәтлелек, сабырлык, диндарлык, игелеклелек, гөнаһлардан саклану, кайгыртучанлык, яхшы вә игелекле гамәлләр кылу кебек сыйфатлар мактала.

Шулай итеп, болгар-татар кабер ташъязмаларында бик борынгы заманнардан ук килгән күркәм кеше идеалы тасвирлана. Җучи Олысы чорындагы кабер ташларына язу төшерү сәнгате Казан ханлыгына да күчкән. Бу вакытларда аларның эчтәлеге һәм бизәлеше тагын да зәвыклырак була бара. Алардагы язулар Аллаһны һәм мәрхүмне данлыйлар, бу дөньяда изге эшләр эшләп калырга өндиләр. Алар ата-бабаларыбызга һәм тарихыбызга зур хөрмәт һәм ихтирам белән сугарылганнар. Кайбер кабер ташларында якыннының югалту ачысы шигъри юллар аша бирелгән. Мәсәлән, 1552 елда вафат булган бер кешенең кабер ташында күңелне тетрәндерә торган шундый юллар уелган:

1. Газраилгә менә шатлык
2. Килде. Бездән шатлык
3. Китте. Мәкерле лачын кебек булып
4.Очты. Табылмас шул сөеклебез
5. Саг(ыш салып) өздe өметебез
6. Мәрхүм хәт(та)
7. Сагышка ба(тып) кит-
8. (Те). Оглан, минем җаным хәсрәт-
9. (тә). Сагышлы мәрхүм,
10. Минем дә, оглан, җаныммы ал".

Бу юллар үлемне бер дөньядан икенче дөньяга күчү итеп аңлата торган, суфичылык белән сугарылган башка язмалардан аерылып тора. Кабер өсләренә куелган ташлар һәм һәйкәлләр изге әйберләр кебек кадерләп сакланганнар. Каберләр өстенә язулы һәйкәлләр кую традициясе безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

*(Ахыры киләсе санда)*

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 5 (174) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35388.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 31 гыйнвар көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**